ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АПАС ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

КАРАРЫ

2025 ел, 17 октябрь №4/1

Җирлекнең җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрен (вәкаләтләрнең бер өлешен) Апас муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына тапшыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Апас муниципаль Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Апас шәһәр җирлегенең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге вәкаләтләрен тапшыру турындагы Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советының тәкъдимен кабул итәргә:

-предметы

1) Россия Федерациясе законнары, Татарстан Республикасы законнары белән административ җаваплылык каралган җирләрдән файдалану өлкәсендә Россия Федерациясе законнарында һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка хокукый актларында билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне юридик затлар, индивидуаль эшкуарлар, гражданнар тарафыннан үтәү

2) рөхсәт документларындагы таләпләрне һәм аларны үтәү Россия Федерациясе законнары нигезендә кирәкле документлар таләпләрен контрольдә тотучы затлар тарафыннан үтәү;

3) контроль чаралар нәтиҗәләре буенча кабул ителә торган карарларны контрольдә торучы затлар тарафыннан үтәү

булган «Апас шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыруга вәкаләтле контроль орган вәкаләтләрен һәм функцияләрен.

2.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Апас шәһәр җирлеге башкарма комитетына:

Апас муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында килешү төзергә;

әлеге карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатларында һәм бюджет законнары нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Апас шәһәр җирлегенең 2025 елга һәм 2026 һәм 2027 елларның планлы чорына Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Апас шәһәр авыл җирлегенең бюджеты турындагы карарга үзгәрешләр кертү турындагы карары проектын карауга тәкъдим итәргә.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга, шулай ук Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының рәсми сайтында җирлек бүлегендә урнаштырырга.

4.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны җирлеге Башлык урынбасары Н.Т. Исмәгыйлевка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Апас муниципаль районы
“Шәһәр тибындагы Апас бистәсе”
муниципаль берәмлеге
башлыгы-
Татарстан Республикасы
Апас муниципаль районы
Апас шәһәр җирлеге Советы
рәисе

А.Г. Җиһаншин